ГЛАВА
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.11.2023 п.г.т. Алексеевское № 72

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турында нигезләмә хакында**

Гамәлдәге законнарга, шул исәптән «Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында» 2003 елның 27 маендагы 58-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында»2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законга , «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында »2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законынына туры китерү максатларында һәм Татарстан Республикасы Президентының 29.01.2016 ел,№ ПУ-61 «Татарстан Республикасы Дәүләт органнарында дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрын һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында «Татарстан Республикасы Президенты Указына үзгәрешләр кертү хакында» Указы белән

## КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турында нигезләмәне расларга (Кушымта).

2. Шәһәр һәм авыл җирлекләре җитәкчеләренә муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибен раслаучы шундый ук карарлар кабул итәргә тәкъдим итәргә.

3. Үз көчен югалткан дип танырга:

-Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башлыгының 29.03.2016 ел, №17 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турында» карары;

- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башлыгының 02.09.2016 ел, №50 «Алексеевск муниципаль районы Башлыгының 29.03.2016 ел, № 17 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турында Нигезләмә хакында» карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары;

- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башлыгының 28.04.2017 ел, №25 «Алексеевск муниципаль районы Башлыгының 29.03.2016 ел,

№ 17 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турында Нигезләмә хакында» карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары;

- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башлыгының 24.01.2019 ел, №7 «Алексеевск муниципаль районы Башлыгының 29.03.2016 ел, № 17 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турында Нигезләмә хакында» карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары;

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында , «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Алексеевск муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе А.Г.Соловьевка йөкләргә.

**Алексеевск муниципаль районы башлыгы** **С.А.Демидов**

Алексеевск муниципаль
районы башлыгының
24.11.2023 ел № 72
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турында нигезләмә.**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә «Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында» 2003 елның 27 маендагы 58-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында»2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законына ярашлы рәвештә һәм «Татарстан Республикасы Дәүләт органнарында дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрын һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында «Татарстан Республикасы Президенты Указына үзгәрешләр кертү хакында» 29.01.2016 № ПУ-61 Татарстан Республикасы Президенты Указы белән Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең реестрларын алып бару эчтәлеген һәм тәртибен билгели.

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрлары Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрнең шәхси эшләреннән алынган мәгълүматлар нигезендә формалаштырыла.

3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрына кертелгән мәгълүматлар, федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары белән билгеләнгән очракларда, конфиденциаль характердагы мәгълүматларга карый һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә якланырга тиеш.

4. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрлары «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтнең кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – мәгълүмат системасы) алып барыла, аларда булган мәгълүматны рөхсәтсез керүдән, юк итүдән, модификацияләүдән, блоклаудан, күчерүдән, тапшырудан, таратудан, шулай ук башка законсыз гамәлләрдән яклауны тәэмин итә .

## II. Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару

5. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрлары мәгълүмат системасында кадрлар эшчәнлеге өчен җаваплы тарафыннан алып барыла.

6. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрын формалаштыру һәм алып бару җирле үзидарә органнарында тәкъдим ителгән муниципаль хезмәткәрләр реестрлары нигезендә мәгълүмат системасында кадрлар эшчәнлеге өчен җаваплы тарафыннан башкарыла.

7. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрлары формалары җирле үзидарә органы җитәкчесе (Татарстан Республикасы муниципаль вазыйфасын биләүче зат) тарафыннан раслана һәм Мәгълүмат системасында урнаштырыла.

8. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрлары үз эченә ала:

муниципаль хезмәткәрнең шәхси мәгълүматлары;

муниципаль хезмәт үтә торган җирле үзидарә органы исеме;

җирле үзидарәнең әлеге органының структур бүлекчәсе исеме;

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестрына туры китереп муниципаль хезмәткәрләр биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасының атамасы;

муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттә кадрлар резервына кертү (кадрлар резервына кертү датасы, вазифа исеме, кадрлар резервына кертү өчен нигез, кадрлар резервынан чыгару өчен нигез).

9. Муниципаль хезмәткәрнең шәхси мәгълүматлары үз эченә ала:

муниципаль хезмәткәрнең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта) турында;

туган көне турында;

һөнәри белем турында (белем бирү оешмасының исеме, диплом номеры һәм датасы, белгечлеге һәм квалификациясе);

хәрби хезмәтне үтү турында;

һөнәри яңадан әзерлек узу турында (белем бирү оешмасының исеме, укуны тәмамлау датасы, программаның исеме, йомгаклау документының төре һәм номеры);

квалификация күтәрү турында (белем бирү оешмасының исеме ,укуны тәмамлау датасы, программаның исеме, йомгаклау документының төре һәм номеры);

гыйльми дәрәҗә турында (гыйльми дәрәҗә исеме, бирелгән дата);

фәнни исем турында (фәнни дәрәҗә исеме, бирелгән дата);

еллар, айлар, көннәр белән исәпләнгән гомуми хезмәт стажы турында;

еллар, айлар, көннәрдә исәпләнә торган муниципаль хезмәт стажы турында;

аттестация узу турында (аттестация уздыру датасы, аттестация комиссиясе карары);

класс чины турында (бирелгән класс чины, аны бирү турында актның датасы һәм номеры);

дәүләт бүләкләре һәм башка бүләкләр турында (бүләк төре, бүләкләү датасы);

муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс узу турында (әгәр граждан конкурс нәтиҗәләре буенча вазыйфага билгеләнгән булса);

хезмәт килешүе турында (төр, хезмәт килешүе төзелгән көн, аның гамәлдә булу вакыты, аңа үзгәрешләр кертелгән көн).

Муниципаль хезмәткәрләрнең шәхси мәгълүматлары исемлеге тулы һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрына карата гына кулланыла.

10. Муниципаль хезмәткә керүче гражданнар турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрына алар муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгәннән соң ике эш көне эчендә җирле үзидарә органнары җитәкчеләре (Татарстан Республикасы муниципаль вазыйфаларын биләүче затлар) актлары нигезендә кертелә.

11. Муниципаль хезмәткәрне шул ук җирле үзидарә органында башка вазыйфага билгеләгәндә аның муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнүе турында белешмәләр җирле үзидарә органы җитәкчесе (Татарстан Республикасы муниципаль вазыйфасын биләүче зат) акты нигезендә Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәрләр реестрына муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгәннән соң ике эш көне эчендә кертелә.

12. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәр турында мәгълүматны муниципаль хезмәткәрләр реестрыннан чыгару өчен нигез булып аны эштән азат итү, Татарстан Республикасы Дәүләт вазыйфасына яки муниципаль хезмәт вазыйфасы булмаган вазыйфага билгеләү, үлем (һәлак булу), шулай ук кешене судның законлы көченә кергән карары белән хәбәрсез югалган яки үлгән дип тану тора.

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәр турында мәгълүматны муниципаль хезмәткәрләр реестрыннан чыгару өчен нигез булып аның башка җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнүе тора.

Муниципаль хезмәттән азат ителгән муниципаль хезмәткәр эштән азат ителгән көнне муниципаль хезмәткәрләр реестрыннан чыгарыла. Муниципаль хезмәткәр үлгән (һәлак булган) яки муниципаль хезмәткәр билгесез рәвештә юк дип танылган яки аны үлгән дип игълан ителгән очракта, муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәткәрләр реестрыннан үлем (һәлакт булган) көненнән соңгы көнне яки суд карары законлы көченә кергән көнне чыгарыла.

13. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәрләр реестрында тиешле үзгәрешләр турында мәгълүмат Мәгълүмат системасына кертелә һәм Департаментка җибәрелә.

14. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт үткән һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрыннан чыгарылган муниципаль хезмәткәрләр турында мәгълүматлар архивка закон нигезендә тапшырыла.

15. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару белән бәйле бәхәсләр закон нигезендә суд тарафыннан карала.

## III. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып баруны тикшереп тору

16. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып баруны контрольдә тотуны җирле үзидарә органы җитәкчесе (Татарстан Республикасы муниципаль вазыйфасын биләүче зат) тәэмин итә. Тикшерү шәхси эшләрнең булу-булмавын һәм аларның торышын тикшерү, Муниципаль хезмәткәрләрнең шәхси мәгълүматларын үз эченә алган мәгълүматларны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәрләр реестрындагы мәгълүматлар белән чагыштыру рәвешендә башкарыла.

Мәгълүматны чагыштыру факты тиешле актта чагыла.

17. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрын формалаштыру һәм алып бару бурычлары йөкләнгән муниципаль хезмәткәрләр закон нигезендә конфиденциаль характердагы мәгълүматларны һәм дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматларны ачу өчен җаваплы.

## IV. Җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрыннан мәгълүмат бирү һәм реестрларны саклау

18. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрлары, аларга үзгәрешләр Мәгълүмат системасында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының җирле үзидарә органнарында кәгазьдә саклана.

19. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрлары, аларга үзгәрешләр Мәгълүмат системасында саклана, аларда булган мәгълүматны рөхсәтсез керүдән, юк итүдән, модификацияләүдән, блоклаудан, күчереп язудан, тапшырудан, таратудан, шулай ук башка законсыз гамәлләрдән яклауны тәэмин итә.

**Район Советының аппарат җитәкчесе** **А.Г. Соловьев**